| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Чукмарлинского сельского поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Чукмарлы авыл җирлеге советы |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 апрель № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1,2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (sarmanovo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге торак пункты территориясендә түбәндәге адрес буенча: Чукмарлы ав., Совет ур., 41 йорт. урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Татарсан Ресаубликасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Хадиуллин

Чукмарлы авыл җирлеге советының
10.04.2025 ел, № 3 карарына
1 нче кушымта

Чукмарлы авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Чукмарлы № 1 | Чукмарлы авылы, Совет ур., йортлар №№ 2-32; 1-33. | 34 |
| 2 | Чукмарлы № 2 | Чукмарлы авылы, Яшьләр урамы, йортлар №№ 10/1-14/2; Совет урамы, йортлар №№ 35-57; 34-44. | 32 |
| 3 | Чукмарлы № 3 | Чукмарлы, авылы, Совет урамы, йортлар №№ 59-93; 46-76. | 42 |
| 4 | Чукмарлы № 4 | Чукмарлы авылы , Комсомол урамы, йортлар №№ 38-60, 17-21; Совет урамы, йортлар №№ 78-92, 97-103. | 37 |
| 5 | Чукмарлы № 5 | Чукмарлы авылы, Комсомол урамы, йортлар №№ 4-36; 1-13. | 38 |
| 6 | Чукмарлы № 6 | Чукмарлы авылы, Яшьләр урамы, йортлар №№ 2/1-8/2; 1/1-11. | 38 |
| 7 | Нарат- Асты № 7 | Нарат Асты авылы , Саях авылы | 35 |

Чукмарлы авыл җирлеге советынь
10.04.2025 ел, № 3 карарына
2 нче кушымта

Чукмарлы авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округларының график сурәте

